СОВЕТ ИМЕНИ ВОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423729,Республика Татарстан, Мензелинский район, п.совхоза им.Воровского, ул. Центральная, 26

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423729, Татарстан Республикасы, Минзәлә район,Воровский ис.совхоз поселогы , Центральный урамы,26

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ВОРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
# КАРАРЫ

№ 2 18.03.2019 ел

## Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы, Воровский исемендәге авыл җирлегенең казна мөлкәте турында Нигезләмәсен раслау турында

Россия Федерациясенең Гражданлык Кодексын, 06.10.2003 елдагы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ, ТР Минзәлә муниципаль районының “Воровский исемендәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын кулланып, ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең казна мөлкәте турында Нигезләмәсен расларга (Кушымта №1).
2. Гамәлдәге карарны ТР Минзәлә муниципаль районының “Воровский исемендәге авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең: http://menzelinsk.tatarstan.ru/rus/vorov.htm рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

ТР Минзәлә муниципаль районының
Воровский исемендәге авыл җирлеге Башлыгы Юдин С.Г.

ТР Минзәлә муниципаль районының
Воровский исемендәге авыл җирлеге
Советы карарына
Кушымта №1
№ 2 дата 18.03.2019

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең казна мөлкәте турында Нигезләмәсе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Гамәлдәге Нигезләмә Россия Федерациясенең Гражданлык Кодексы нормалары, 06.10.2003 елдагы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль Законы, ТР Минзәлә муниципаль районының "Воровский исемендәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнгән, һәм максатларны, бурычларны, составны һәм финанс чыганакларын билгели, шулай ук Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль казна составына керүче муниципаль мөлкәтне учетка алу, идарә итү һәм эш итү тәртибен билгели.

1.2. Гамәлдәге Нигезләмәнең тәэсире Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджетының акчалата чараларын үз эченә алган казна өлешенә, шулай ук акцияләргә һәм хуҗалык җәмгыятьләренә (өлешләр), Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең башка кыйммәтле кәгазьләренә һәм бурычларына кагылмый.

1.3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Воровский исемендәге авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге исеменнән Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль казнасын эченә алган муниципаль мөлкәткә карата милек хуҗасының хокуклыгын Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты башкара.

1.4. Казна мөлкәтен формалаштыру һәм исәпкә алу, шулай ук күчемсез милеккә муниципаль казнаны эченә алган муниципаль хосусыйлыкка хокукларга дәүләт теркәве өчен кирәкле чараларны Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Минзәлә муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән башкарма комитет җитәкчесе урынында Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты башкара.

## 2. Казна мөлкәтен формалаштыруның, исәпкә алуның, муниципаль казна белән идарә итү һәм эш итүнең максатлары һәм бурычлары

3. Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең казна мөлкәтен формалаштыруның, исәпкә алуның, муниципаль казна белән идарә итү һәм эш итүнең төп максатлары түбәндәгеләр:

- Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең икътисадый нигезен ныгыту;
- муниципаль хосусыйлык объектыннан коммерция максатларында кулланудан Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджетының керемнәрен арттыру;
- Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең хосусыйлык объектларын саклау, кабаттан торгызу һәм арттыру;

- Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге территориясенә инвестицияләр җәлеп итү һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген стимуллаштыру;
- Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең гражданлык-хокукый килешүләр буенча бурычларын тәэмин итү.
2.2. Казна составына кергән мөлкәт белән идарә һәм эш иткәндә максатларны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:
- муниципаль казна мөлкәтен һәм аның хәрәкәтен объектлап исәпкә алу;
- муниципаль казна мөлкәтен саклау һәм арттыру;
- Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджетына өстәмә чаралар җәлеп итү;
- муниципаль хосусыйлык объектларын торгызуга финанс чараларын туплау;
- Халыкның ихтыяҗларын тәэмин итү өчен кирәкле мөлкәтне Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль хосусыйлыгы составында саклап калу;
- мөлкәттән файдалануның аеруча нәтиҗәле ысулларын куллану;
- муниципаль мөлкәтнең саклanышына һәм максатчан кулланылышына контроль.

## 4. ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге казнасы мөлкәте составына кертелгән мөлкәт

4.1. Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге казнасы мөлкәте составына (алга таба – Казна милке) Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыкта булган һәм хуҗалык алып бару хокукында муниципаль унитар предприятиегә, оператив идарә итү хокукында муниципаль унитар предприятиегә беркетелмәгән күчемсез һәм күчемле мөлкәт керә, шул исәптән:
- ликвидацияләнгән унитар предприятиеләр һәм учреждениеләрнең милек комплекслары;
- юридик затларда, шулай ук хуҗалык җәмгыятьләрендә бушлай файдалануда булган социаль кулланылыштагы мөлкәт;
- арендада яки коммерцияле оешмаларда яисә шәхси эшмәкәрләрдә ышанычлы идарәдә булган мөлкәт;
- Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең күчемсез милек объектларына гомуми өлешле хосусыйлык хокукында өлеше;
- муниципаль унитар предприятиеләрнең яисә муниципаль учреждениеләрнең оператив идарә итү хуҗалык алып баруыннан законда билгеләнгән очракларда алынган мөлкәт;
- башка законлы нигезләмәләр буенча Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгына кергән мөлкәт.
3.2. Казна мөлкәте составына кертелергә тиешле мөлкәт:
а) Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджеты хисабыннан муниципаль хосусыйлыкка турыдан-туры яңадан булдырылган һәм сатып алынган;
б) законда каралган тәртиптә, федераль яисә республика хосусыйлыгыннан муниципаль хосусыйлыкка күчерелгән (күчемсез милек – дәүләт теркәве узган вакыттан аңа хосусыйлыкка хокуклар күчү);
в) юридик һәм физик затлар тарафыннан муниципаль хосусыйлыкка бушлай тапшырылган (күчемсез милек – дәүләт теркәве узган вакыттан аңа хосусыйлыкка хокуклар күчү);
г) Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль учреждениеләре һәм муниципаль унитар предприятиеләренең оператив идарәсеннән алынган һәм хуҗалык алып барудан чыгарылган;

д) Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль учреждениеләрен һәм муниципаль унитар предприятиеләрен ликвидацияләү процессында кредиторларның таләпләрен канәгатьләндергәннән соң калган;
е) башка законлы нигезләрдә муниципаль хосусыйлыкка кергән, шул исәптән, Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең гамәлдәге законнар нигезендә хосусыйлык хокукы барлыкка килгән җир кишәрлекләре.
3.3. Гамәлдәге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән чыганаклар хисабыннан Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең казна мөлкәте составына кертелүе аның алга таба кулланылышын, аны карап тотуга һәм эксплуатацияләүгә чаралар бүлеп бирү күләмен һәм тәртибен билгеләүче Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлеге җитәкчесенең карарлары нигезендә башкарыла.

## 4. Казна мөлкәте объектларын исәпкә алу

4.1. Казна мөлкәте объектларын исәпкә алу һәм аларның хәрәкәте Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте Реестрының тиешле бүлегенә мәгълүматлар кертү юлы белән башкарыла.
Әлеге бүлектә объектның атамасы, сан һәм сыйфат характеристикалары, аның бәясе һәм таушалуы, сатып алу ысуллары, учетка кую сроклары һәм нигезләмәләре, кирәк булганда, башка мәгълүмат, оешманың бухгалтерлык исәбендә мөлкәтнең аерым төрләрен чагылдырганда бухгалтерлык исәбе турындагы законнарның тиешле таләпләре, шулай ук мөлкәтне куллануга тапшыру буенча карарларның, башка актларның, мөлкәт белән эш итү буенча килешүләр буенча, шул исәптән, мөлкәтне казна мөлкәте составыннан чыгаруга һәм аны казнага кире кайтаруга китерүче мәгълүматларны үз эченә ала.
4.2. Казна мөлкәте Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең идарә итү органнарының бухгалтер исәбендә һәм башка муниципаль оешмаларда чагылырга тиеш түгел (норматив хокукый актларда турыдан-туры каралган очраклардан тыш).
Казна мөлкәте объектларын муниципаль унитар предприятиеләрнең яки муниципаль учреждениеләр оператив идарәсенең хуҗалык алып баруына тапшырганнан соң, әлеге предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан аларны балансска кую башкарыла һәм закон билгеләгән тәртиптә бухгалтерлык учеты алып барыла.
Казна мөлкәте объектын предприятие һәм учреждение тарафыннан балансска куйганда, аның казна мөлкәте составында булу срогы һәм калдык бәясе, беренчел (баланс) бәясе мәгълүматлары нигезендә объектның мөлкәти казна составында булган чоры эчендә амортизация суммасын бер тапкыр исәпләү һәм өстәп түләү уздырыла.
Казна мөлкәте объектларын бушлай файдалану килешүләре, аренда килешүләре һәм закон билгеләгән нигездә төзелгән башка килешүләр нигезендә кулланучыларга тапшырган очракта, Казна мөлкәте объектларына карата бухгалтерлык учетын алып бару бурычы килешү текстына тиешле шартларны кертү юлы белән, әлеге кулланучыларга йөкләнә.
Казна мөлкәте объектлары кулланучылар тарафыннан ай саен амортизацияне исәпләп, билгеләнгән форма буенча инвентарь карточкаларын мәҗбүри ачып баланс счетында исәпләнә.
Муниципаль казна объектлары турындагы мәгълүматларны Реестрда үзгәртү андый үзгәрешне раслаучы тиешле документларны кәгазь һәм электрон кучергечләрдә муниципаль казна объектларыннан файдаланучылар тапшырган нигездә Вәкаләтле орган тарафыннан уздырыла.
4.3. Вәкаләтле орган гамәлдәге закон билгеләгән тәртиптә Казна мөлкәте составына кертелгән күчемсез милек объектлары буларак җир кишәрлекләреннән даими (сроксыз) файдалану хокукын рәсмиләштерә.

4.4. Вәкаләтле орган ел саен, еллык отчет тапшыру өчен финанс органы тарафыннан билгеләнгән сроктан соң булмаган срокта, натураль һәм акчалата эквивалентта Казна мөлкәте составы һәм үзгәрешләре турында отчет формалаштыра.

4.5. Казна мөлкәте учеты мәгълүматларының дөреслеген тәэмин итү өчен даими рәвештә казна инвентаризациясе уздырыла, аның барышында мөлкәтнең барлыгы һәм аның торышы документаль тикшерелә.

## 5. Казна мөлкәте объектлары белән идарә һәм эш итү

5.1. Казна мөлкәте объектлары Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, гамәлдәге Нигезләмәдә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең норматив хокукый актлары билгеләгән тәртиптә һәм шартларда кулланыла.

5.2. Казна мөлкәте булган муниципаль хосусыйлык объектлары приватизацияләнә, килешү буенча арендага тапшырыла, ышанычлы идарә яисә бушлай файдалануга, залогка, саклануга, хуҗалык җәмгыятьләренең устав капиталына вклад сыйфатында кертелә, муниципаль унитар предприятиеләрнең хуҗалык алып баруына, муниципаль учреждениеләрнең оператив идарәсенә тапшырыла, шулай ук Воровский исемендәге авыл җирлегенең закон чыгаручы һәм норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Минзәлә муниципаль районы Воровский исемендәге авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә башка гражданлык-хокукый килешүләр предметы булырга мөмкин.

5.3. Казна мөлкәте объектларыннан файдаланган өчен аренда түләве һәм башка керемнәр Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджетына күчерелергә тиеш.

## 5. Объектларның казна мөлкәте составыннан чыгуы.

6.1. Объектларның Казна мөлкәте составыннан чыгуы түбәндәге очракларда башкарыла:

- аларның хуҗалык алып бару һәм муниципаль унитар предприятиеләргә оператив идарә хокукында беркетелүе. Объектларны федераль хосусыйлыкка, Татарстан Республикасы хосусыйлыгына, башка муниципаль берәмлек хосусыйлыгына тапшыру;
- гражданлык-хокукый килешүләр кысаларында тартып алу (приватизацияләү, сату, бүләк итү, алмаштыру);
- суд караларын үтәү;
- объектның юкка чыгарылуы;
-объектка хокукларның югалуы.

6.2. Муниципаль хосусыйлыктан чыккан объектлар Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең муниципаль мөлкәт Реестрына тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән Казна мөлкәте составыннан чыгарылырга тиеш.

6.3. Гамәлдәге Нигезләмәнең 6.1 пунктында күрсәтелгән очракларда Казна мөлкәте составыннан чыккан объектларны төшереп калдыру ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең карары нигезендә башкарыла.

## 7. Казна мөлкәте объектларын вакытлыча чикләү

Казна мөлкәте составында булган муниципаль хосусыйлык объектлары законда каралган тәртиптә ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты карары буенча вакытлыча чикләнергә мөмкин:

- Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге йөкләмәләрен, шул исәптән, Минзәлә муниципаль районының йөкләмәләре буенча залог белән тәэмин итү;
- сервитутлар һәм объектның үзенчәлекләре белән бәйле башка чикләүләр белән;

- суд карарлары буенча йөкләмәләрне үтәү нәтиҗәсендә;
- арест салу нәтиҗәсендә;
- аерым төр объектлардан файдалану буенча өченче затларның хокуклары белән.

7.2. Чикләү асылы, Казна мөлкәте объектын гражданлык әйләнешендә вакытлыча чикләү Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль мөлкәт Реестрында объектларны учетка алу язмасында чагыла.

**8. Казна мөлкәте объектларына бәя бирү**

8.1. Казна мөлкәте объектларына бәя бирү кыйммәттә белдерелгән мөлкәтне исәпкә алуны чагылдыру өчен башкарыла.

8.2. Учет актларында база буларак соңгы отчет датасына баланс мәгълүматлары буенча баланс кыйммәте кулланыла.

8.3. Гражданлык-хокукый килешүләр өчен бәяли торган эшчәнлек турында Россия Федерациясе законнары кулланыла.

8.4. Казна мөлкәте объектларына бәя бирү Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән түләнә.

**9. Муниципаль хосусыйлык хокукларына дәүләт теркәве**

9.1. Казна мөлкәтенең күчемсез милек объектлары Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте Идарәсенең Татарстан Республикасының Минзәлә бүлегендә Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль хосусыйлыгына хокукларга дәүләт теркәве узарга тиеш.

9.2. Казна мөлкәтенең җир кишәрлекләре Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография Федераль хезмәте Идарәсенең Татарстан Республикасының Минзәлә бүлегендә Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге муниципаль хосусыйлыгына хокукларга дәүләт теркәве узарга һәм кадастр учетына бастырылырга тиеш.

9.3. Кадастр учеты өчен дәүләт теркәвенә документлар пакетын формалаштырган өчен түләү ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджеты хисабыннан башкарыла.

**10. Казна мөлкәте объектларын карап тоту, саклап тоту, реновация һәм ремонтлауны тәэмин итү**

10.1. Казна мөлкәте составына кертелгән хосусыйлык объектларын карап тоту, эксплуатацияләү, реновация һәм ремонтлауга чыгымнар Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары белән расланган нормативлар буенча башкарыла.

10.2. Физик һәм юридик затларга файдалануга һәм (яисә) биләүгә тапшырылмаган Казна мөлкәте объектларын эксплуатацияләүгә чыгымнар, Казна мөлкәте объектларын төзек хәлдә тоту һәм сакланышын тәэмин итү җирле бюджет хисабыннан башкарыла һәм ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

10.3. Куллануга һәм биләүгә тапшырылган мөлкәтне карап тоту һәм эксплуатацияләү яклар килешүе белән башкача каралмаган очракта, беркетелгән физик һәм юридик затлар тарафыннан башкарыла.

10.4. Хуҗасыз, вариссыз калган һәм башка мөлкәтне муниципаль итеп тануга һәм суд тарафыннан танылуга чыгымнар законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджеты хисабыннан башкарыла.

## 11. Йомгаклау нигезләмәләре

11.1. Казна мөлкәте объектларыннан хуҗалык әйләнешендә файдаланудан алынган финанс чаралары ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге бюджетына әйләнеп кайта.

11.2. ТР Минзәлә муниципаль районының Воровский исемендәге авыл җирлеге Башкарма комитеты яисә вәкаләтле орган судка шикаять белән түбәндәге сораулар буенча мөрәҗәгать итәргә хокуклы:

- объектларга муниципаль хосусыйлык хокукын тану һәм аларны чит законсыз биләүдән кабат алу;
- Казна мөлкәте объектлары белән килешүләрнең гамәлдә булмавын тану;
- аренда түләве буенча бурычларны түләтү һәм Казна мөлкәте объектларына аренда килешүләрен өзү;
- Казна мөлкәте буенча физик һәм юридик затларның законсыз гамәлләре белән китерелгән чынлыктагы зыян һәм башка чыгымнарны түләтү;

11.3. Казна мөлкәтенең саклanышына һәм максатчан кулланылышына контрольне ТР Минзәлә муниципаль районының “Контроль-исәп палатасы” МКУ башкара.

## 12. Вазифаи затларның җаваплылыгы һәм гамәлләренә һәм берни эшләмәүләренә шикаять бирү тәртибе

12.1. Вазифаи затларның җаваплылыгы һәм гамәлләренә һәм берни эшләмәүләренә шикаять бирү тәртибе гамәлдәге законнар белән билгеләнә.